| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2022г. с. Тюлячи № 159

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 елның 29 декабрендәге 880 номерлы «Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярый ярдәм (волонтерлык) турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 340-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 880 номерлы «Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ихтыярый ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеге оештыручылар, ихтыярый ярдәм (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек Тәртибенә:

3 пунктта:

1) дүртенче абзацта "күрсәтү" сүзен "гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә катнашуда, янгыннарны профилактикалауда һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрен уздыруда, шулай ук хезмәтләр күрсәтүдә" сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"гражданнарның хәбәрсез югалган затларны эзләүдә катнашуы.".

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ф.С. Вәлеев